СОВЕТ
НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯР БУЕ МОРКВАШЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

24.09.2018 с. Набережные Моркваши № 62-264

**Яр буе Моркваши авыл җирлеге территориясендә гражданнар үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдумны билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22 ст., 56 ст. нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 ст. 1 п. 1 пункты, Яр буе Моркваши авыл җирлеге Уставының 11 ст. карары нигезендә «Җирле референдум уздыру инициативасы турында» 2018 елның 21 сентябрендәге 61-261 номерлы Яр буе Моркваши авыл җирлеге Советы карары нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Моркваши авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. 2018 елның 18 ноябренә Яр буе Моркваши авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга:

"2019 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия авыл җирлегенең һәр кешесеннән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару буенча алынган акчаларны юллау белән килешәсезме:

- Яр буе Моркваши авылында балалар мәйданчыклары төзү;
- Пустые Моркваши бистәсендә балалар мәйданчыгы төзү;
- Десятидворка бистәсендә урамнарны яктыртуны реконструкцияләү;
- Никольский бистәсендәге юлга вак таш җәю;
- Покровка авылында урамнарны яктыртуны реконструкцияләү, контейнер мәйданчыгы төзү;
- Урман Моркваши авылы зиратына кадәр юлны ремонтларга.

ӘЙЕ ЮК

3. «Волжская новь» район газетасында әлеге карарны бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, Югары

Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Яр буеМорквашы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Яр Буе Морквашы авыл җирлеге башлыгы _______________ И.Х. Гаязов